СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 10 » март 2026 ел № 6

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар КАБУЛ ИТТЕ:

1. Утар-Аты авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Арча муниципаль районының “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен раслау һәм Арча муниципаль районының “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү турында” 2017 елның 13 сентябрендәге 38 номерлы карар.

- “Арча муниципаль районының “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү һәм Арча муниципаль районының “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль

вазыйфаларны һәм Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 сентябрендәге 38 номерлы карары белән расланган контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына мәгълүмат бирү турында” 2021 елның 3 августындагы 33 номерлы карар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1121690069165 МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «УТАР-АТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ИНН 1609012621
СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ